**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «КЕЧЕ БӨГЕЛМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ IV ЧАКЫРЫЛЫШ**

**XLI СЕССИЯСЕ**

**2 нче Карар**

**Кече Бөгелмә авылы, «15» декабрь, 2023 ел**

**«Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Кече Бөгелмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмә» хакында 2019 елның 14 октябрендәге Кече Бөгелмә авыл җирлеге Советының XLVII сессиясенең 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96.6 һәм 220.1 статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2024 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларының үтәлеш үзенчәлекләрен билгеләү турында"гы 520-ФЗ номерлы Федераль законга, муниципаль берәмлек уставына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының “Кече Бөгелмә авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Советы

Карар кабул итте:

1. 2024 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Кече Бөгелмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәнең 27 статьясындагы 4 пунктының 7 абзацын Кече Бөгелмә авыл җирлеге Советының 14.10.2019 елгы XLVII сессиясенең 1 номерлы карары белән расланган гамәлдә булуын туктатып торырга.
2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Кече Бөгелмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртиптә бастырылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башлыгы В. Б. Григорьев**